**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422701 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, 113А йорт

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422701, Республика Татарстан, Высокогорский
район,с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, д. 113А

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79 e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**10 апрель 2025 ел** **№ 445**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 11.11.2019 елның № 619 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 04.02.2025 № 02-08-01 протесты нигезендә, Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 11 ноябрендәге 619 номерлы карарына (Советның 19.05.2020 № 671, 07.06.2022 № 203, 15.07.2022 № 211, 29.08.2022 №222, 24.11.2022 №244, 24.11.2022 №247, 16.11.2023 №318, 28.12.2023 №334, 17.12.2024 №413 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2 пунктчасындагы 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш, әлеге абзацта индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләрен һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләрен;»

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://vysokayagora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы А.А. Хабибуллин